СӨЙ ГОМЕРНЕ, СӨЙ ХАЛЫКНЫ, СӨЙ ХАЛЫКНЫҢ ДӨНЬЯСЫН!

# ДУСЛЫК

ОКТЯБРЬ РАЙОНЫ ИҖТИМАГЫЙ - СӘЯСИ ГАЗЕТАСЫ.
ОБЩЕСТВЕННО-ПОЛИТИЧЕСКАЯ ГАЗЕТА ОКТЯБРЬСКОГО РАЙОНА.

12сентябрь, 1997ел.
ҖОМГА

Газета 1931 елның 9 июленнән бирле чыга. | № 102 (8114) | Бәясе билгеләнгәнчә

# Район тормышы: кешеләр, вакыйгалар, фактлар

## Мөһим мәсьәләләр каралды

Узган чәршәмбедә район хакимиятендә урып - җыю кампаниясен үткәрү буенча актив - шәһәр предприятиеләре һәм учреждениеләре җитәкчеләре катнашында киңәшмә узды. Аны үткәргән район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин районда урып - җыю эшләренең, дәүләткә ашлык тапшыруның барышын җитди анализлады. Бу җәһәттән ул «Норлат» агрофирмасында эшнең начар оештырылуын каты тәнкыйтьләде.

Фатих Сәүбәнович залдагыларны республика районнарының ашлык хәзерләү сводкасы белән таныштырып, Татарстан Республикасы Президенты М.Ш.Шәймиевның Октябрь районы хезмәтчәннәренең бу юнәлештәге эшен югары бәяләвен белдерде, урып - җыю кампаниясен үткәрү активы, уракта катнашкан һәркемгә рәхмәт җиткерде. Шул ук вакытта хакимият башлыгы урып - җыю эшләрен якын көннәрдә тулысынча тәгәлләү, ындыр табакларындагы ашлыкны ташуны эзлекле оештыру, моның өчен шәһәрдәге бөтен төр йөк автотранспортын мобилизацияләү кирәклеген дә ассызыклады. Бу уңайдан активның һәръяклы практик ярдәменә таяначагына өмет белдереп, алар алдына конкрет бурычлар да куйды.

Киңәшмәдә кукурузны үзвакытында урып - җыю, туңга сөрүне тизләтү буенча да зур сөйләшү булды. Кукуруз урдыру механизмнарының барысына да ревизия үткәреп, төзәтеп кую, яшел масса ташу өчен җитәрлек күләмдә автотранспорт туплау зарурлыгына игътибар юнәлтелде. Туңга сөрүне якын көннәрдә тәгәлләү өчен барлык төр трактор техникасын бу эшкә мобилизацияләү һәм аларның хезмәтен ике сменада оештыру кирәклегенә басым ясалды.

Ф.С.Сибагатуллин шикәр чөгендерен җыеп алу мәсьәләсенә хәзерлеккә дә киң тукталды. Сүз уңаенда бу эшкә сентябрьнең урталарында керешү отышлы булачагын билгеләде.

Киңәшмәдә шулай ук районда автомобиль юллары төзүгә кыскача анализ да ясалды.

## Бар эштә дә оста



Нефтебазаның ярдәмче хуҗалыгында Петр Михайлович Семенов турында бер кешедән дә начар сүз ишетмәссең. Гомерлек игенче, техниканың да төрлесендә эшләп үзен күрсәтте. Соңгы ун ел рәттән комбайнчы булды, бер генә уракта да сынатмады.

Быел тракторга утыргач та сер бирми. Әле менә җәй көне сабанчыларның район конкурсында хуҗалык данын яклап чагыштырмача әйбәт нәтиҗә күрсәтте. Бу көннәрдә Т - 150 тракторында Алексей Алексеевич Максимов белән алмашлап туңга сөрүдә алар. Тегесе көндез эшләсә, Петр Михайлович төнге сменада. Смена нормасын тутырмый калганнары юк, кыскасы бу эшнең үзләреннән торганын башкаруда сүз әйтергә урын калдырмыйлар.

Бу җаваплы эшкә читтән китерелгән К - 700 тракторында эшләүче Дмитрий Леонтьевич Совковның хезмәтеннән дә канәгатьләр хуҗалыкта. Хуҗалык мөдире буларак көндез шул мәшәкатьләр артыннан йөри ул, ә төнге сменада трактор руле артына утыра.

Хуҗалыктагы барлык техниканы да туңга сөрүдә шулай нәтиҗәле файдаланганда бу мөһим эшне тагын да тизрәк тоту мөмкинлеге бар.

**Рәсемдә: нефтебаза ярдәмче хуҗалыгы механизаторы П.М.СЕМЕНОВ.**

**Н.КВАШНИНА фотосы.**

## ЮЛЛАРЫНА БӘХЕТ ЯУГЫРЫ

- Сезнең өчен иң җаваплы йөк нинди?

Шоферларның байтагы аңа ашлык, икмәк диячәк.

Шөкер, соңгы елларда урак чорында юлларда анда - санда сибелеп яткан ашлыкка сирәк тап буласың. Моны күпмедер дәрәҗәдә юлларның яхшыруы белән бәйләп булса да, шоферларның машина әрҗәләрендәге йөккә карата булган җаваплылыкларын, хөрмәтләрен аерым билгеләмәү мөмкин түгел. Әнә, Василий Васьков. Чагыштырмача яшь шофер әле ул. Төп эш урыны - машина төзү заводы. Тимер - томыр күчерүгә гадәтләнгән егет быел элеваторга ашлык ташу буенча үзәкләштерелгән автоотряд составында эшли башлагач, икенче яктан ачылды: икмәккә сак мөнәсәбәттә, өстәвенә бик җәһәт тә эшли икән. Хезмәттәше Юрий Кольцов белән икәү «Татарстан», «Алга», «Әлмәт» кебек ерак хуҗалыкларга көнгә берничә тапкыр барып, ашлык алып кайталар.

Үзәкләштерелгән автоотряд составында эшләгәндә танышкан дуслары - НУРБ шоферлары Андрей Крайнов һәм Марс Төхфәтуллин да өлгер шоферлар итеп таныттылар үзләрен. УТТдан Валерий Мелихов, АТПдан Гомәр Ибраһимов, профессиональ - техник училищедан Александр Харитонов та уттай урак өстендә бер генә сәгатьләрен дә бушка үткәрмәделәр: алар да хуҗалыклар ындыр табакларыннан элеваторга ашлык ташыдылар. Хуҗалыклардан икмәк ташуны оештыру өчен җаваплы кеше - авыл хуҗалыгы продуктлары ташу буенча штаб начальнигы М.Әхмәдиев та мактап туя алмый үзләрен.

Гомумән, урып - җыю эшләре чорында автотранспорт зур урын тота. Әйтергә кирәк, быел бу эшләр көйле оештырылды. Августның 26сыннан ашлык ташу буенча игълан ителгән удар ункөнлек чорында гына да район хуҗалыкларыннан элеваторга 30 мең тоннадан артык ашлык китерелүе дә шул хакта сөйли. Иң мөһиме, авыл эшчәннәренә бу эштә шәһәрлеләр дә зур ярдәм күрсәтә. ДРСУ, НУАД кебек оешмалар кызу юл төзү сезоны булуга да карамастан, авыл эшчәннәренә автотранспорт белән ярдәм итәргә атлыгып торалар. НУРБ администрациясе дә авыл эшчәннәренең хәленә керә. Ә менә МСОлар башкаларга булышу түгел, ярдәмче хуҗалыкларында тупланган ашлыкны да үзвакытында элеваторга илтүне оештырмыйлар.

**Р.МИНАПОВА.**

## Хакимият башлыгы котлый

**Район хакимияте башлыгы Ф.С.Сибагатуллин быелгы урып - җыю эшләрендә фидакарьлек үрнәкләре күрсәтеп эшләүчеләргә котлау хатлары җибәрә тора. Бу көннәрдә комбайнчылар Зәкиулла Кәлимуллович Хәйбуллин («Киекле»), Евгений Александрович Фомин («Төрнәс»), Павел Иванович Варламов («1 нче Май»), тракторчы Сергей Евгеньевич Фомин (Синдряков исем.), пешекче Нажия Насыйховна Сабирова («Чирмешән») нәкъ шундый хатлар алдылар. Хакимият башлыгы аларны хезмәт җиңүләре белән котлап, һәркайсына уңышлар, саулык - сәламәтлек, иминлек тели.**

## Туңга сөрүне ашыктырасы бар

***Район хуҗалыкларында 10 сентябрьгә туңга сөрү планының үтәлеше ( процентларда)***

| | | | |
|---|---|---|---|
| «Таң» | 56 | «40 лет Победы» | 39 |
| «Якты Күл» | 54 | «Заря» | 37 |
| «Дуслык» | 54 | РСУ ярд. хуҗ. | 36 |
| «Рассвет» | 52 | Синдряков исем. | 36 |
| Миурин исем. | 49 | М.Җәлил исем. | 35 |
| «Чирмешән» | 49 | Нефтебаза ярд. хуҗ. | 33 |
| «Заветы Ильича» | 49 | «Киекле» | 32 |
| «Родина» | 48 | «Алга» | 30 |
| «Анрохимсервис» ярд.хуҗ. | 46 | Шикәр заводы ярд.хуҗ. | 28 |
| «1 нче Май» | 45 | «Игенче» | 26 |
| «Кондырча» | 43 | «Әлмәт» | 25 |
| «Төрнәс» | 43 | «Комбайн» | 24 |
| Агропромбанк ярд. хуҗ. | 43 | «Үрнәк» | 22 |
| МСО ярд. хуҗ. | 42 | «Татарстан» | 17 |
| Кузнецов исем. | 41 | | |
| Сөт - май комбинаты ярд. хуҗ. | 40 | Район буенча | 38 |

Туңга сөрүнең бүгенге темплары һич тә канәгатьләнерлек түгел. Соңгы бер атна вакыт эчендә эшкәртелгән мәйдан 7 мең гектардан аз гына артыграк һәм көненә мең гектар гына дигән сүз бит бу. Ә туңга сөрүне оптималь срокларда тәмамлау өчен көн саен кимендә 2 мең гектар җир эшкәртергә кирәк. Дөрес, соңга таба эш темпы азрак арта төште. 9 сентябрьдә район буенча туңга сөрүдә 130 берәмлек техника файдаланылып, шуның 76сы ике сменада эшләтелде. Шунысы игътибарга лаек, сөрүдә энергия куәте югары тракторлар саны арта төште һәм 26 К - 700нең барысы да диярлек нигездә ике сменада эшлиләр. «Якты Күл», «Таң», «Чирмешән», «40 лет Победы», «Родина» хуҗалыкларында барлык техника ике сменада эшләтелә, «Киекле», «Заветы Ильича»да да агрегатларның күбесе көне - төне файдаланыла. Әмма агрегатларның гомуми җитештерүчәнлеге гаять түбән булган хуҗалыклар бар әле. «Игенче», «Комбайн», «Үрнәк», Муса Җәлил исемендәге һәм кайбер башка хуҗалыкларда барлык техника диярлек, шул исәптән беренче өчесендә К -700лар дә берәр генә смена эшләтелгәндә, кайбер хуҗалыкларда уңайлы һәм киң алынлы француз сабаннары да файдаланылмаганда моңа гаҗәпләнәсе дә юк. Тик менә, белгечләр исәпләвенчә, эшнең бүгенге темплары сакланганда шикәр заводы ярдәмче хуҗалыгында туңга сөрү... кыш уртасына, ә Муса Җәлил исемендәге хуҗалыкта... март башына тәгәлләнәсе икәнлеге генә уйландырырлык. Темпны арттырмаган тәкъдирдә «Әлмәт», «Үрнәк», МСО ярдәмче хуҗалыгында да туңга сөрү тагын ай ярымга сузылырга мөмкин әле.

Туңга сөрү кебек җитди эшне тоткарлаучы объектив сәбәпләр дә, ягулык - майлау материаллары белән дә зур тоткарлыклар булганы юк - соңгысын оператив төстә хәл итеп торалар. Димәк, урыннарда эш оештыруга тирәнрәк анализ белән җитдиерәк карау сорала.

### Терлекчелек кышка карый

## Алдан аяк киенделәр

**Көннәр бер көзгә керөп киттеме, малларны ничек тә абзарга кайтару турында кайгыртырга кирәк - иртәме - соңмы барыбер башкарасы ул эшне пычрак һәм салкыннарга калдырмыйча, коры көннәрдә уздырып калу мөһим.**

«Родина» КХАсында быел нәкъ шулай иттеләр дә - савым көтүен районда беренче булып кышкы торакларына кайтардылар. Хәзер ташлаткан сыерлар да үрчем китерергә әзерлек чоры рационы буенча ашатыла, ремонтланган абзарларга кайтарылган савым сыерлар да урын һәм ризык алыштыруны әллә ни сизмәделәр төсле - хуҗалык дәүләткә сөт сату күләмен киметмәү түгел, бераз арттыра да төште - бүген бу хуҗалыктан хәзерләүләр пунктына 1700 килограммнан күбрәк продукция керә.

**II Бөтендөнья татар конгрессыннан соң**

# МИЛЛИ БАЛКЫШНЫҢ БЕР БИЗӘГЕ

***Казанда II Бөтендөнья татар конгрессы уңаеннан Үзәк стадионда оештырылган бәйрәмдә безнең Октябрь районы вәкилләре дә катнаштылар.***

Киңкырлы бай татар мәдәнияты, сәнгате, милли гореф - гадәтләре турында сөйләгәндә төрле диаспора - керәшен татарлары, мишәрләр һ.б мәдәнияты яктыртылмый калса, татар дөньясы һич тулы ачылды дип әйтеп булмас иде. Шунлыктан конгресс барышында Үзәк стадионда оештырылган бәйрәмдә мишәрләр өчен аерым «урам» билгеләнүне бик урынлы дип санадык. Анда кергән 5 район кысаларында без дә үз сәләтебез - осталыгыбызны күрсәтергә тиеш идек. Район хакимиятенең мәдәният бүлеге мишәр туй йоласы күренешен әзерләргә булды. Моның өчен махсус сценарий төзелде, иң сәләтле үзешчәннәр сайлап алынды. Иң зур хезмәт бу җәһәттән Бикүле, Норлат халык театры артистлары җилкәсенә төште. Алар әлеге күренешне бар нечкәлекләренә кадәр халыкка җиткерү өчен халкыбызның кул эшләре үрнәкләре - чигүле мендәр тышлары, суккан паласлар, сөлгеләр, челтәрле тәрәзә пәрдәләре дә тупладылар. Шулар белән бизәлгән авыл өе күренеше күпләрне җәлеп итеп, чыгышыбызны табигый һәм үтемле иткәндер дә, мөгаен. Шуңа халыкка йола күренешен күрсәткәннән, үзебезнең артистларыбыз (алар арасында Норлат балалар музыка мәктәбенең вокаль ансамбле дә бар иде) чыгыш ясаганнан соң да безнең сәхнә гөрләп торды: мишәр урамы чыгышы үзәге итеп нәкъ безне сайладылар. Шул сәхнәдән артистлар Искәндәр Биктаһиров, Габдулла Рәхимкулов, Исламия һәм Хәлил Мәхмүтовлар, Мирсәет Сөнгатуллин кебек талантлы җырчылар, биюче якташыбыз Халисә Шәрәпова, нәфис сүз остасы Рәшит Шамкай чыгыш ясадылар. Безнең чатырда танылган сәнгать, фән әһелләре Зилә Сөнгатуллина, Клара Хәйретдинова, Индус Таһиров, Нәбирә Гыйматдинова, Ислам Әхмәтҗанов кунак булып, үз уңай фикерләрен белдереп киттеләр. Ә сәхнә чыгыш ясаучылардан бушамады. Район данын күрсәтергә дип барган иң нәни артистларыбыз Ленар Әһлиуллиннан алып, гармунчы Вәгыйзь ага Галимов, Рәфыйк ага Хәмзинга чаклы ару - талуны белмичә барлык чараларда да актив булдылар. Казан кунакларына мишәр сый - нигъмәтләрен авыз иттерү, аларны ачык йөз белән сыйлау НГДУ эшчеләрне тәэмин итү бүлегенә йөкләнгән иде, кызлар аны намус белән башкарып чыктылар. Гомумән, «Норлатнефть» НГДУсына без тирән рәхмәтлебез: бәйрәмдә катнашу өчен чатырны да, төп техниканы да, озатырга омончы егетләрне дә алар бер авырсынусыз бирделәр.

Стадионда гөрләгән бәйрәмдә шулай безнең район үзешчәннәре дә үз йөзләрен, үз осталыкларын күрсәтеп кайта алдылар. Моннан тыш, бездән С.Ефремова җитәкчелегендәге «Родник» ансамбле дә бик актив эшләде конгресс көннәрендә. Алар берничә көн алдан барып, берничә җирдә чыгыш ясарга өлгергән иделәр инде. Бәйрәм көнне дә иң үзәктә кайнадылар: бәйрәм кунаклары һәм Татарстан Президентын каршы алуда, кичке массовый чарада алар үз халыкларының лаеклы вәкилләре булдылар. Мондый мәдәният энтузиастларына ничек сокланмыйсың да, рәхмәт әйтмисең ди? Берочтан район үзешчәннәре чыгышын югары сәнгать дәрәҗәсендә әзерләүгә күп көч куйган мәдәният бүлеге мөдире Р.Н.Яруллин, халык театры режиссеры К.Зәбиров, Норлат музыка мәктәбе директоры Т.Бадыйгин, хакимиятнең социаль - культура бүлеге әйдәп баручы белгече Р.Сөнгатуллинага да, чыгышларда катнашкан үзешчән артистларга да рәхмәт белдереп, иҗат уңышлары телисе килә.

Казанда гөрләгән республика бәйрәме, Татар конгрессы чараларын телевидение аша күзәткән, радиодан тыңлаган якташларыбызның шунда бәлки берaз хәтерләре дә калгандыр: ә нишләп бездә бәйрәм булмады? Чыннан да, төп иҗат көчләре анда тартылганлыктан, районда бәйрәм чараларын бераз соңрак вакытка - октябрь башларына күчерергә карар кылынды. Кыр эшләре тәмамлангач, көзге сабантуй рәвешендә уздырылачак бу бәйрәм эшчән якташларыбызга чын ял, күңел ачу китерер дип уйлыйбыз. Соңгысын тәэмин итүдә үзешчән артистларыбыз тырышлыкларына шикләнмибез. Башкала кадәр башкалада зур татар дөньясында үз йөзләрен күрсәтергә сәләтле талантларыбыз якташлары хөрмәтенә тырышлыкларын кызганмаячаклар, әлбәттә!

**Ф.НОГЪМАНОВА,**
**район хакимияте башлыгының социаль - мәдәни мәсьәләләр буенча урынбасары.**

---

**Хафизов исемендәге КХА - барлык тармакларда да тотрыклы эшләүче хуҗалык. Быел уракны районда беренчеләрдән булып, яхшы нәтиҗәләр белән тәмамлаулары да шул хакта сөйли.**

## Чебешләре- ... кәзен санарлык!

Әлеге хуҗалыкка чәчү өстендә дә, аннан соң да килергә ниятләп караган идек.

- Чебешләрне кәзен саныйлар. Уракны тәмамлагач, уңышлар турында да, кулдан ычкындырылган резервлар хакында да сөйләшү реаль булачак,- дип каршы төшә килде ассоциация рәисе В.Ф.Булатов.

Инде менә чебешләрне санар чак җитте. Әйтергә кирәк, алар санарлык һәм хаклы рәвештә горурланырлык та икән. Узган ел да районда бөртекле һәм бөртекле - кузаклы культуралардан иң югары уңыш үстерүчеләрнең берсе булган Хафизов исемендәге КХА быел аны һәр түгәрәктән уртача тагын 15,4 центнерга арттырып 44,3 центнерга җиткергән.

Шунысын да әйтәсе килә, хафизовлылар уракны да районда беренчеләрдән булып төгәлләделәр бит. Югыйсә, бөртекле һәм бөртекле - кузаклы культуралар чәчелгән мәйданнар гына да 2.388 гектар тәшкил итә иде. Урып - җыю эшләрен тиз тоту өчен кызу да, маневрлап та эшләргә туры килде. Шулай итмәсәң, һәр комбайн үзенә төшкән нагрузка - 200 гектарда эшне ай - һай озакка сузган булыр иде.

Афәрин, хафизовлылар! Дәүләткә икмәк сату заданиесен дә тиз арада үтәделәр бит әле.

## Җиргә бирсәң чын күңел

Хуҗалык рәисе Валерий Федорович моны җир, аның белән эшләүне уңышка ирешүнең төп алшарты буларак билгеләде.

Сүз дә юк, җир белән күңел биреп, җиренә җиткереп эшли беләләр бирәдә. Югары игенчелек культурасы хуҗалыгы дигән исем йөртүләре зур вазифа да йөкли. Шуңа да бу эшкә үтә җаваплы карыйлар хуҗалыкта. Үз, сыналган тәҗрибәләреннән чыгып бөртекле һәм бөртекле - кузаклы культураларны аркылыга - буйга гына чәчәргә тырышалар. Сөрү, башка төрле чараларның барысы да ГОСТ таләпләренә туры килә. Бу җәһәттән, соңгы елларда кулланыла торган француз сабанының да ярдәме күп тиде хуҗалыкка. Узган ел туңга сөреләсе мәйданнарның 1200 (!) гектарын шуның белән эшкәрттеләр.

Машина төзү заводында ясалган культиваторга да сөенеп бетә алмыйлар хафизовлылар. Әнә быел яз туфракны шуның белән генә эшкәртеп тырмаламыйча да күмдерәләр орлыкны. Никадәр ягулык - майлау материаллары янга калды, вакыт, акча экономияләнде.

- Дүрт бригаданың һәркайсында шундый берәр культиватор булса бөтен эшне алар белән башкара алыр идек,- дип хыялланалар механизаторлар.

Күп нәрсә шулай хыялда гына кала шул әлегәчә. Соңгы елларда лизинг буенча алынган ДТ - 75 һәм ике МТЗ - 82 тракторларын санамаганда, калган барлык техника да, кем әйтмешли, мамай заманыныкы. Аларын да яңарта алсалар, хәлләр хәерләнә дә әле анысы...

Шулай да, моңа әлләни борчылмыйлар хуҗалыкта: ил бәласе бит, бер аларга гына хас проблема түгел. Шөкер, әле шушы, туган туфракларында үзләре, үз көчләре



Рәсемдә: данлыклы игенче В.Е.Донсков менә ул!
Н.АЗИЗОВ ФОТОСЫ.

белән, күңел биреп көн күрәләр. Шулай булмаса, ачы җирләрне известьлап, технология нигезендә сөреп, орлык күмдерелгәннән алып - үсемлекләр шытканчы һәм шыткач, вегетация чорында, гомумән, башаклар тулганчы шул басуда булмаслар иде... Әнә быел үсемлекләрне шытканчы да, шыткач та тукландырдылар. Чүп үләннәре һәм корткычларга каршы нәтиҗәле чараларын да күргәч кырлар карап туйгысыз булды. Билгеле инде, монда ашламалар белән эшләү үз сүзен әйтми калмады, җир кайгыртучанлыкка юмарт җавап бирде.

## Бәяләрлектә, олыларлык та

Ни генә дисәк тә, уңышны хәл итүче төп фактор - кеше.

- Балык башыннан чери, диләр. Җитәкчеләр, белгечләр тискәре үрнәк күрсәтсә, әйдәүче көч була алмыйлар. Шуңа да белгечләргә таләп зур бездә,- ди бу уңайдан Валерий Федорович. Сүз дә юк. Әгәр дә игенчелек башында Хәниф Җәмалов кебек «җир алласы» тормаса, баш инженер Александр Паруков техниканың теләсә нинди вакытта сәгать механизмыдай эшләвен тәэмин итмәсә, хуҗалык уракны беренчеләрдән булып тәмамлый алыр идемени?! Чуваш Мәнҗесе игенчеләре хуҗалыкта иң югары уңыш үстергәннәр икән, монда кооператив җитәкчесе яшь, энергиясе ташып торган Виктор Сергеевның өлешен ничек бәяләмисең дә, хезмәтен олыламыйсың ди инде!

Донсковлары тагын! Дөнья бәясе торырлык кеше бит. Исеме республика күләмендә яңгырый башлавына да дистә елга якын инде. Александр Егорович быел да район кыр батырлары исемлегенең беренче графасында. Аныкы кебек үк «ДОН»да эшләүчеләр Анатолий Булатов, Илья Паруковны әйт тагын! Соңгысына пенсиясен алып җылы өендә генә утыру мөмкинлеге булса да, кендеге белән шушы җиргә береккән игенченең йөрәге түзә мени!

Өлкән яшьтәге механизаторлар Сабир Җәлалов һәм Алексей Михайлов, Сергей Таймуллин, быел кыска вакыт эчендә Америка тракторы «Магнум» белән 1.000 гектарга якын җир сөргән Әхәт Гыйниятуллин һәм Газинур Ганиев хуҗалыкның төп терәге булырлык искиткеч тырыш, булган кешеләр. Шуңадырмы, мөһим кампанияләр чорында да кемне дә булса яннан китереп эшләтү - хуҗалык өчен ят нәрсә: үз көче, үз мөмкинлеге белән көн күрә бирүдәге халык. Шулар белән көчле хуҗалык, шундыйлар белән бердәм.

***

Басулары бушап бара хуҗалыкның. Кыр патшасы - кукуруз, «татлы» культура - шикәр чөгендере кырларыннан кала барлык басулар да кара тәскә кергән. (Оптималь агротехник срокларда 486 гектарда уҗым чәчелгән, һәр гектарга 2 центнер исәбеннән катлаулы ашлама кертеп, шуның 320 гектарына орлык аркылыга - буйга күмдерелгән). Өметле булып яшел үсентеләр борын төртеп килә. Туңга сөреләсе мәйданнар да күзгә күренеп кими. Биеклеге өч метрга якын «үрләгән» кукуруз басуында исә эш кайный: силоска урдырыла ул. Чөгендер кырының да иң җанлы хезмәт участогы буласы көннәренә күп калмады. Ә плантацияләргә карап туймассың: кара кучкыл, шыгырдап тора торган зур, киң яфраклы чөгендернең берсе - берсе генә дә 450 - 470 грамм тартырлык!

- Былтыр район дәүләткә саткан шикәр чөгендеренең 11 проценты безнең хуҗалыкныкы иде, быел да кимен куймабыз шәт,- ди В.Булатов.

Өмет аклансын, икмәккә генә түгел, шикәр чөгендере уңышына да сөенергә насыйп итсен иде ходай, дип, шул теләккә кушылабыз без дә.

**Р.ГИНЯЕВА.**

## Безнең календарь

**Татар драматургиясенең классигы, күренекле артист һәм режиссер Кәрим Тинчуринның туума 110 ел (1887 - 1947)**



### Сәхнә әдәбиятыбызның классигы

Кәрим Гали улы Тинчурин - 1910 елда беренче татар профессиональ театр труппасы «Сәйяр»гә актер булып эшкә урнашу көненнән башлап үзенең бөтен гомерен, көч - сәләтен театр сәнгатен һәм драматургиясен үстерүгә багышлаган фидакарь шәхесләребездән берсе. Ул - актер да, режиссер да һәм иң мөһиме - татар сәхнә әдәбиятын классика дәрәҗәсендәге гүзәл әсәрләр белән баетучы драматург. Аның «Беренче чәчәкләр», «Сүнгән йолдызлар», «Американ», «Җилкәнсезләр», «Зәңгәр шәл» һ.б. пьесалары заман үткән саен тагы да тамашачыларны дулкынландырып, сәхнәдә яшәүләрен дәвам итәләр. Әдип үз язмышына туры килгән афәтле заманның мәкерле киртәләренә, идеологик кысуларга, янауларга карамастан, иҗаты һәм сәхнәдәге эшчәнлеге белән татар театр сәнгатен яңа югарылыкка күтәрде.

Ләкин утызынчы елларда тоталитар режим оештырган репрессияләр афәте аны да үзенең аяусыз тырнагына эләктереп алды һәм 1938 елның 15 ноябрендә олы талант иясенең вакытыннан элек гомерен кисте.

# Үткән юлы данлы

Әйбәт кешеләргә безнең ветераннар сафы бик бай. Аларның күбесен мин эш буенча, ветераннарның район Советы эшчәнлекләрендә катнашуым аркасында беләм. Миңа Николай Иванович Маслаков бик яхшы таныш, аның белән бергә «Восход» колхозында (анда ул 20 ел председатель булып эшләде) эшләргә туры килде. Хуҗалык аның кулына бик таушалган хәлдә эләкте, ул аны аякка бастырды, ә кайбер күрсәткечләр буенча алдынгылар рәтенә дә чыгарды. Ул халык белән киләчәкне даими күздә тотып эшләүдән туктамады, авырлыклардан зарланырга яратмады, алар җитәрлек булган очракта еш кына мондый сүзләрне кабатлый иде: «авыр дип тормаска, куллар сөялләнгәнче эшләргә кирәк һәм нәтиҗәсе һичшиксез булачак.»

Ничектер, язгы кыр эшләреннән соң без аның белән янә кырларга чыктык. Аннан соң янәшә тау битенә утырдык. Биредән Андреевка авылы уч төбендә төсле күренә. «Бик матур авыл,- ди Николай Иванович,- һәм кешеләр дә әйбәтләр. Ә ничек үзгәртеп корылды ул бу еллар эчендә: яңа терлекчелек комплекслары, мехмастерской, гараж, мәдәният йорты, ике катлы мәктәп, медпункт, балалар бакчасы, ашханә, механизаторлар өчен торак йортлар, асфальт түшәлгән юллар... Шунда мин аңардан сорап куйдым: бу тормышта нәрсә ярата ул, нәрсә сөендерә аны? «Ә шатлыкны миңа гаиләм китерә. Өч кызым һәм ике улым бар».

Сөйләшү шунда ватанпәрвәрлек темасына кереп китте. «Әгәр кеше бу тойгылардан мәхрүм икән, димәк, аның Ватаны юк. Ватанпәрвәрлек сугыш елларында разведкачы - солдатларга бик нык булышты. Польша, Венгрия, Чехословакияләрне сугышлар белән үтәргә туры килде, берничә тапкыр үлем белән йөзгә - йөз очрашырга, ике тапкыр авыр җәрәхәт алырга туры килде...» Фашист автоматчылары Николай Ивановичны теткәләп бетерсәләр дә, ул хәрби позициясен ташламады. Н.И.Маслаков сугышчан батырлыклары өчен ике Дан, ике Ватан сугышы ордены һәм бик күп санда сугышчан медальләр, ә намуслы хезмәте өчен - Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде.

Еш кына миңа мәктәпләрдә тематик кичәләрдә, хезмәт коллективларында, хәрби комиссариатта хезмәткә чакырылучы яшьләр белән очрашырга туры килә. Анда мин үземнең истәлекләрем, уй - фикерләрем белән уртаклашам. Күргәнегезчә, сугышта катнашучыларны вакыт аямый, үзләре исән чакта аларны белергә һәм тыңларга кирәк. Ә хәтердә исә яшь буын өчен гаять әһәмиятле күп истәлекләр саклана. Без, ветераннар ватанпәрвәрлек яшьләр өчен буш тавыш булмас, ата һәм бабаларыбыз батырлыгы онытылмас дип өметләнәбез.

**А.ДМИТРИЕВ,**
**сугыш һәм хезмәт ветераны.**
**Норлат шәһәре.**

# КОТЛЫЙБЫЗ!



Чулпан авылында яшәүче ***әтиебез Каим Сәмигулла улы һәм әниебез Мәрьям Хәсәнҗан кызы Сәмигуллиннарның*** 14 сентябрьдә бергә гомер итүләренә 50 ел тула. Әти, әни, без сезне алтын туегыз белән котлыйбыз. Без алты балагызга Сез һәрвакыт булдыгыз терәк, йөз яшәгез, әти, әни, безгә сез һәрчак кирәк.

***Барлык балаларыгыз, кияүләрегез, киленнәрегез һәм оныкларыгыз исеменнән улыгыз Рәсих.***

Норлат шәһәрендә яшәүче кадерле ***әниебез һәм туганыбыз Рәйсә Гаязетдин кызы Хәсәновага*** 15 сентябрьдә 40 яшь тула. Аны юбилее белән котлыйбыз. Ныклы сәламәтлек, кояштай озын гомер телибез.

***Изге теләкләр белән тормыш иптәшең, улың һәм туганнарың.***

# Ничек сөекле булырга?

Кайсы хатын - кыз бу сорауга җавап эзләми икән! Хәер, мең төрле киңәшен дә табарга була, ләкин аларның һәркайсы бер мөһим кагыйдәне эченә ала: сөекле булу өчен үзең дә яратырга кирәк. Ничекме? МЕНӘ СЕЗГӘ БОРЫНГЫ ӘБИЛӘРЕБЕЗНЕҢ БЕРНИЧӘ КИҢӘШЕ. Аларны тотсагыз, хәтта холыксызрак тоелган ир - ат белән дә бәхетле яши алырсыз.

***ҺӘР КӨННЕ БАШКА БУЛА БЕЛ.*** *Чөнки ир - ат хатынының чын асылын төшенә, аның ниндилеген гел белеп бетерә алмый. Шуңа күрә иреңне гаҗәпләндерү, исен китәрү әллә ни авыр эш түгел. Мәсәлән, ак төстәге эчке күлмәктән син ир күңелен күбрәк җәлеп итәрсең. Бүген болай, иртәгә тегеләй сөйләвен дә ярата икән ир - ат хатын - кызның. Әбиләребез ирләрен моның ише «вак - төяк» белән шаккаттырырга бик яратканнар. Шуңа күрәдер инде, бабаларыбыз гомер буе: «Иң яхшы хатын - кыз миңа эләкте»,- дип уйлап яшәгәннәр.*

***ЙӨРӘККӘ ЮЛ - АШКАЗАНЫ АША.*** *Әнисе имезсә, бала елаудан туктый. Тамагы тук ир дә бик сирәк ачулана. Һәм тәмле ашка алданып, хатынына әллә нинди ташламалар ясап куя.*

***АНЫ ТЫНЫЧЛАНДЫРА БЕЛ.*** *Ир - атлар тумыштан ук шикләнүчән холыклы. Күкрәге чәнчесә, ул инфаркт көтә башлый. Температурасы күтәрелсә, үпкәдәдер ди.*

*«Дипломат» хатын - кызлар белә бу очракта нишлисен. Иренең өстенә йомшак юрган япкан була ул, зыянсыз һәм файдасыз дару эчергән була, хәленә кереп, башыннан сыйпый. Һәм... бер сәгать тә үтми, «авыру» инде аяк өстендә.*

***АКЫЛЛЫ БУЛ, ҖҮЛӘР БУЛЫП КЫЛАН.*** *Безнең әбиләр ирләренә нәрсә ошавын, үзләрен ничек тотарга кирәклеген яхшы белгәннәр. Укытучылар кебек: мәсьәләнең чишелешен укучыдан яхшырак белә, ләкин алдан әйтми. Укучының дөрес чишелешкә үзе килгәнен көтә. Шул ук вакытта аңа, бик сиздермичә генә үзем таптым дип уйларлык итеп юнәлеш тә бирә.*

***АҢА БАЛАГА КАРАГАН КЕБЕК КАРА.*** *Ир - ат, хатын - кыздан аермалы буларак, һәрвакыт сабый булып кала. Игътибар итсәгез, ирегезнең холык - табигатендә малайлыктан калган ниндидер сыйфат табарсыз. Ачуланмагыз. Аны ничек бар, шулай кабул итәргә тырышыгыз... Шул чакта гына сез ирегезнең яраткан хатынына әверелерсез.*


## Белдерүләр

### Сатабыз

**Ашыгыч рәвештә кирпеч йортның икенче катында телефоны да булган фатир сатыла.**
Адрес: Дружба ур., 17.

***

**Цинкланган, кара түбә калае, 2 х 1,5 метрлы капка тимере, гараж капкалары.** Адрес: Димитров ур., 7, тел.: 5 - 41 - 64.

***

**Ашыгыч рәвештә ВАЗ - 2106**. Җиңүнең 50 еллыгы микрорайоны, 2 - 6.

***

**Материаллары белән 5 х 3 метрлы мунча, 1979 елгы «Нива» автомашинасы.** Тел.: 4 - 32 - 28 (Елаурда).

***

**Ашыгыч рәвештә 2 бүлмәле фатир.** Адрес: Завод ур., 25 - 8.

***

**Вишневая Поляна авылында йорт.** Рус Мәнҗесе авылында Олопов Валерийга мөрәҗәгать итәргә.

***

**6 х 1,30 размерлы 25 данә цинкланмаган профнастил, бәясе - килешү буенча**. Адрес: Киров ур., 10, (17.00дән 20.00гә кадәр).

***

**Ашыгыч рәвештә шәһәр уртасында 2 бүлмәле фатир.** Эш телефоны - 2 - 11 - 49 (8.00дән 17.00гә кадәр).

***

**Чистарту корылмалары районында базы белән гараж.** Адрес: Кормыш поселогы, Восточная ур., 11 - 12.

### Төрлесеннән

**Фатирга кертеп торабыз.**
Телефоннар: эшнеке - 2 - 27 - 36, өйнеке - 5 - 16 - 14.

***

**Октябрь райпосы азык комбинатына даими эшкә аммиакта эшләүче суыткыч җайланмалары машинисты кирәк. Белешмәләр өчен директорга мөрәҗәгать итәргә.**
Тел.: 2 - 21 - 15, 8.00дән 17.00гә кадәр).

### Тәкъдим итәбез

**Акрынлап һәм җәфа чикмичә тартуны ташларга теләүчеләр өчен чара:**
**- чәй агачы мае - дәвалау сыйфатлары, көчле авыртуны һәм кан агуны туктату сәләте белән киң таралган уникаль чара.**
Тел.: 2 - 13 - 49, 2 - 22 - 97. Лицензия - Б - 97 № 054293.

**«Девон - Кредит» АБсы хезмәт күрсәтү киңәю турындагы белдерүгә (газетаның 1997 елның 3 сентябрь санында чыккан иде) өстәмә кертә: коммуналь хезмәтләр өчен түләү бары тик НГДУ ЖКХсы хезмәт күрсәтә торган йортларда яшәүчеләр өчен генә башкарыла.**

### Фотосөючеләр игътибарына!

***«ЭКСПРЕСС - ФОТО» фотосалонында һәрвакыт әйдәп баручы җитештерүче фирмалар (FUJI, AGFA, KONICA, KODAK) фототасмалары, фотоальбомнар, KODAK һәм OLIMPVS фотоаппаратлары, батареялар һәм башка фотоәйберләр өчен чехоллар бар. Бәяләре - шәһәрдә иң арзан.***

***«ЭКСПРЕСС - ФОТО» ДА АЛЫНГАН БАРЛЫК ТАСМАЛАР БУШЛАЙ АЧЫКЛАНДЫРЫЛА. Фотоларны басуга заказлар 1сәг.тән 1 тәүлеккә кадәр, фотоларны ачыкландыруга - 1 сәг.кә кадәр вакытка үтәлә.***

### Компьютер ияләре игътибарына!

«ЭКСПРЕСС - ФОТО»салонында ЭВМнарны комплектлаучы һәм оргтехникага чыгым материаллары сату бүлеге ачылды. Сатуда HDD, FDD, mouse, key - bord,SVBA видеоплаталары, тавыш платалары, актив колонкалар, CD - ROM дисководлары, джойстиклар, принтерлар һәм ксерокслар өчен картриджлар, COANON өчен тонер , факс һәм ксерокс өчен кәгазь, буяучы тасмалар, саклагычлы компьютер тройниклары, CDга уен һәм уку - танып - белү программалары, укыту һәм тар белгечлекле әдәбият һ.б. бар.

Шулай ук ЭВМнарга вак ремонтлар үткәрәбез (өстәмә җайланмалар кую, ЭВМны модернлау, төзексез узелларны алыштыру, көйләү һ.б.) «CANON» ксерокслары өчен картриджлар тутыру принтерлары өчен тасмалар буяу һәм башкалар.

Лицензия номеры - Б 97054163, Б 97054162.

Эш сәгатьләре - 9дан 18.00гә кадәр. Төшке ял - 13.00дән 14.00гә кадәр. 1997 елның 1 августыннан - ял көннәрсез.


Кизләү урта мәктәбе коллективы мәктәпнең элеккеге укытучысы **Затия Нуриәхмәт кызы Вафинаның** тормыш иптәше Рәшит Нургата улы Хөснетдиновның вафат булуы сәбәпле тирән кайгысын уртаклаша.

Камыр - Батыр мәктәбенең 2А класс укытучысы һәм ата - аналары уллары Данис үлүе сәбәпле, **Мәсгутов Минкаюм белән Алсуның** тирән кайгысын уртаклаша.


БАШ МӨХӘРРИР **Р.Ф.ҖАМАЛИЕВ.**
МӨХӘРРИР **С.Н.ХӘЙРУЛЛИНА**

**Учредительләр: Октябрь район хакимияте һәм редакциянең хезмәт коллективы.**

"Дуслык" район газетасы атнаның чәршәмбе, җомга, шимбә көннәрендә чыга, рус һәм чуваш телләренә тәрҗемә ителә.

Безнең адрес: 423000, Татарстан Республикасы, Норлат шәһәре, Карл Маркс урамы,19.

Телефоннар: баш мөхәррир - 2-12-14, 2-22-81, мөхәррир һәм авыл хуҗалыгы бүлеге - 2-22-51, Советлар һәм җәмәгать оешмалары тормышы, чуваш теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-10-44, җаваплы сәркәтип - 2-18-67, рус теленә тәрҗемә буенча мөхәррир - 2-14-16, бухгалтерия,реклама бүлеге, фотокорреспондент - 2-15-63.

*Газета Татарстан Республикасының мәгълүмат һәм матбугат Министрлыгында 34 нче номерлы таныклык белән теркәлде.*

Ульяновск өлкәсе матбугат һәм мәгълүмат идарәсенең Димитровград типографиясе. Офсет ысулы белән басылды. Күләме - 1 басма табак. Тираж 2336 данә. Заказ N 8717.